РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ КАМАЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МЕНДЕЛЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

423643, РТ, Менделеевский район,
с.Камаево, ул. Дифгата Сирая д.29А

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КАМАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

423643 , РТ, Менделеевск районы,
Камай авылы, Дифгать Сирай урамы 29А йорты

Тел./ факс: 8(85549) 3-55-33, E-mail: Kam.Men@tatar.ru

---

РЕШЕНИЕ КАРАР

2021 елның 10 июненнән № 33

Муниципаль вазыйфа яисә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар, муниципаль вазыйфалар яисә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характерындагы йөкләмәләре хакында белешмәләр бирү тәртибе турында

«Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы һәм «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законнар, , «Муниципаль вазыйфа яисә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалучы гражданнар, муниципаль вазыйфалар яисә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характерындагы йөкләмәләре хакында белешмәләр бирү тәртибе турында» 2017 елның 19июлендәге 56-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан республикасы Менделеевск муниципаль районы “Камай авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Иске Тинчәле авыл җирлеге Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Расларга:

1.1. Муниципаль вазыйфа яисә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар, муниципаль вазыйфалар яисә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характерындагы йөкләмәләре хакында белешмәләр бирү тәртибе турында Нигезләмәне (1 нче Кушымта)

1.2. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Камай авыл җирлегендә муниципаль вазыйфалар билгеләнгәндә гражданнар өчен үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирү мәҗбүри булган һәм шулай ук вазыйфаны биләгәндә дәүләт граждан хезмәткәрләре өчен үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти

характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирү мәҗбүри булган дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында", һәм хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирү мәҗбүри булган дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген (2 нче кушымта)

2. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Камай авыл җирлеге Советының 2016 елның 23 мартындагы 22 номерлы «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы «Камай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүгә дәгъва кылучы гражданнарның керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан керемнәре, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турында " гы карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны http://pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм http://mendeleevsk.tatarstan.ru Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында "Камай авыл җирлеге" бүлегендә урнаштырырга.
4. Камай авыл җирлеге Советының социаль-мәдәни мәсьәләләр, законлылык, хокук тәртибе һәм Кеше хокуклары буенча комиссиясенә әлеге карарның үтәлешен контрольдә тоту йөкләнә.

Камай авыл җирлеге башлыгы И.И.Әһлиева

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Камай авыл җирлеге Советының 2021 ел 10 нчы июненнән 33 номерлы карарына 1 НЧЕ КУШЫМТА

Муниципаль вазыйфа яисә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар, муниципаль вазыйфалар яисә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләр бирү тәртибе турында Нигезләмә

**1 статья. Әлеге Нигезләмәнең җайга салу предметы**

1. Әлеге Нигезләмә, 2008 елның 25 декабрендәге «Коррупциягә каршы тору турында»гы № 273-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131- ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә муниципаль вазыйфа яисә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар, муниципаль вазыйфалар яисә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфаларын биләүче затларның, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре (алга таба - керемнәр, чыгымнар, милек һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр) тапшыру тәртибен билгели.

2. Әлеге Нигезләмә муниципаль сайлаулар нәтиҗәләре буенча гамәлгә ашырыла торган муниципаль вазыйфаларны биләүгә дәгъвачыларның керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирүгә бәйле мөнәсәбәтләргә кагылмый.

**2 статья. Керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат тапшыру тәртибе һәм сроклары**

1. Керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характерындагы йөкләмәләр турында белешмәләр, әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән, Федераль законнар нигезендә расланган белешмә формасы буенча, муниципаль вазыйфа яисә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар, муниципаль вазыйфаларны яисә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан тапшырыла.

2. Әлеге статьяның 1 өлешендә каралган белешмә Татарстан Республикасы Президентына керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү өчен махсуслаштырылган мәгълүмат ресурсы аша тутырыла һәм тапшырыла (dohod.tatar.ru). Күрсәтелгән белешмәнең күчермәсе муниципаль вазыйфаны яисә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар, контракт буенча муниципаль вазыйфаларны яисә җирле администрация башлыгы вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан имзаланган кәгазьдә, тиешле муниципаль районда (шәһәр округында) коррупцион һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы вазыйфаи затка җибәрелә һәм законнар нигезендә сакланырга тиеш.

3. Федераль законда башкасы билгеләнмәгән булса, муниципаль вазыйфа яисә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүгә дәгъва кылучы граждан түбәндәгеләрне тапшыра:

1) муниципаль вазыйфаны биләү өчен документлар тапшыру елына кадәрге календарь ел өчен барлык чыганаклардан алынган керемнәре (элеккеге эш урынындагы

яисә сайланулы вазыйфаны биләү урынындагы керемнәрне, пенсияләрне, пособиеләрне, башка түләүләрне кертеп) турында белешмәләр, шулай ук аның милек хокукындагы мөлкәте турында һәм граждан муниципаль вазыйфаны биләү өчен документлар тапшыру аена кадәрге айның беренче числосына (хисап датасына) булган мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр;

2) гражданның муниципаль вазыйфа, контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләү өчен документлар тапшыру елына кадәрге календарь ел өчен хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының барлык чыганаклардан алынган керемнәре (хезмәт хакын, пенсияләрне, пособиеләрне, башка түләүләрне кертеп) турында белешмәләр, шулай ук граждан муниципаль вазыйфа, контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләү өчен документлар тапшыру аена кадәрге айның беренче числосына (хисап датасына) милек хокукындагы мөлкәте турында һәм аларның мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр;

3) җир кишәрлеге, башка күчемсез мөлкәт объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр (оешмаларның устав (тупланма) капиталларындагы катнашу өлешләре, пайлар) сатып алуга кагылышлы һәр алыш-биреш буенча үз чыгымнары, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары (оешмаларның устав (тупланма) капиталларындагы катнашу өлешләре, пайлар) турында белешмәләр, әгәр мондый алыш-бирешләрнең гомуми суммасы әлеге затның һәм аның хатынының (иренең) хисап чорына (1гыйнвардан 31 декабрьгә кадәр) кадәрге соңгы өч елдагы гомуми кеременнән артып китсә һәм әлеге алыш-бирешләрне башкару чыганаклары хакында.

4. Муниципаль вазыйфаны биләүче зат, авыл җирлекләренең вәкиллекле органнары депутатларының муниципаль вазыйфаларын даими нигездә биләгән һәм үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы затлардан тыш, яисә җирле администрация башлыгы вазыйфасын контракт буенча ел саен, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү өчен билгеләнгән срокта тапшыра:

1) хисап чорында (1 гыйнвардан 31 декабрьгә кадәр) барлык чыганаклардан алынган керемнәре (акчалата бүләкләүне, пенсияләрне, пособиеләрне, башка түләүләрне кертеп) турында белешмәләр, шулай ук аның милек хокукындагы мөлкәте турында һәм хисап чоры ахырына торышы буенча мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр (31 декабрьгә кадәр);

2) хисап чорында (1 гыйнвардан 31 декабрьгә кадәр) алган хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының барлык чыганаклардан (хезмәт хакын, пенсияләрне, пособиеләрне, башка түләүләрне кертеп) керемнәре турында белешмәләр, шулай ук алар милек хокукында булган мөлкәт турында һәм хисап чоры ахырына аларның мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр (31 декабрьгә кадәр);

3) җир кишәрлеге, башка күчемсез мөлкәт объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр (оешмаларның устав (тупланма) капиталларындагы катнашу өлешләре, пайлар) сатып алуга кагылышлы һәр алыш-биреш буенча үз чыгымнары, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары (оешмаларның устав (тупланма) капиталларындагы катнашу өлешләре, пайлар) турында белешмәләр, әгәр мондый алыш-бирешләрнең гомуми суммасы әлеге затның һәм аның хатынының (иренең) хисап чорына (1гыйнвардан 31 декабрьгә кадәр) кадәрге соңгы өч елдагы гомуми кеременнән артып китсә һәм әлеге алыш-бирешләрне башкару чыганаклары хакында.

4.1. Авыл җирлеге вәкиллекле органы депутатының муниципаль вазыйфасын биләүче һәм даими булмаган нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы зат «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар һәм аларның керемнәренә, чыгымнарына, мөлкәтенә һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләренә туры килүен тикшереп тору турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясындагы 1 өлешендә каралган алыш-бирешләрнең хисап чоры дәвамында башкарылган очракта, депутат булып сайланган көннән алып дүрт ай эчендә керемнәр, чыгымнар, мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында, аңа вакантлы депутат мандатын тапшырган яисә даими нигездә вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны туктаткан көннән алып дүрт ай дәвамында, шулай ук белешмәләр тапшыру елыннан алдагы һәр ел өчен (хисап чорына) белешмәләр тапшыра. Хисап чоры дәвамында мондый килешүләр башкарылмаган очракта, күрсәтелгән

зат бу хакта әлеге Нигезләмәнең 2 өлешендә каралган, кушымта нигезендә форма буенча, махсус мәгълүмат ресурсын кулланып, хәбәрнамәне җибәрү юлы белән Татарстан Республикасы Президентына хәбәр итә. Әлеге пунктта каралган хәбәрнамәләр, шулай ук белешмәләр («Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясындагы 1 өлешендә каралган килешүләр хисап чоры дәвамында башкарылган очракта) Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү өчен билгеләнгән срокта бирелә.

Авыл җирлегенең вәкиллекле органы депутаты муниципаль вазыйфасын биләүче һәм үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы зат тарафыннан имзаланган кәгазьдә хәбәрнамәнең күчермәсе тиешле муниципаль районда (шәһәр округында) коррупцион һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы вазыйфаи затка җибәрелә һәм законнар нигезендә сакланырга тиеш.

5. Әгәр әлеге Нигезләмә нигезендә үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр биргән граждан муниципаль вазыйфа буенча вәкаләтләр бирелмәгән булса (күрсәтелгән муниципаль вазыйфага билгеләнмәгән, сайланмаган), контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасына билгеләнмәгән булса, бу белешмәләр аның язма гаризасы буенча кире кайтарыла.

**3 статья. Керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында төгәлләштерелгән мәгълүмат бирү**

1. Муниципаль вазыйфа яисә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы граждан, муниципаль вазыйфа яисә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче зат, керемнәре, чыгымнары,мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында тапшырылган белешмәләрдә нинди дә булса мәгълүматның булмавын яисә тулысынча булмавын, яки хаталар булуын ачыклаган очракта, алар Татарстан Республикасы Президентына әлеге Нигезләмәдә каралган тәртиптә керемнәре, чыгымнары, милке һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында төгәл мәгълүматлар (алга таба - төгәлләштерелгән белешмәләр) тапшырырга хокуклы.

2. Контракт буенча муниципаль вазыйфаны яисә җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүгә дәгъва итүче граждан күрсәтелгән белешмәләрне биргән көннән бер ай эчендә төгәлләштерелгән белешмәләрне тапшырырга хокуклы.

3. Контракт буенча муниципаль вазыйфа яисә җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче зат әлеге Нигезләмәнең 2 статьясындагы 4 һәм 4.1 өлешләрендә күрсәтелгән сроклар тәмамланганнан соң, бер ай эчендә, төгәлләштерелгән белешмәләрне тапшырырга хокуклы.

**4 статья. Керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат тапшырмау яки белә торып дөрес булмаган яки тулы булмаган белешмәләр биргән өчен җаваплылык**

1. Муниципаль вазыйфаларны яисә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче затларның керемнәре, чыгымнары, милке һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар тапшырмау, шулай ук муниципаль вазыйфаларны яисә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче затлар белеп тә дөрес булмаган яки тулы булмаган белешмәләр бирүләре өчен Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплы булалар.

2. Муниципаль вазыйфаны яки контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче затның керемнәре, чыгымнары, милке һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматларны объектив сәбәпләр аркасында тапшыру мөмкинлеге булмау турында гариза Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан билгеләнә торган тәртиптә каралырга тиеш.

3. Җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты, керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яки тулы булмаган мәгълүмат биргән депутатка, әлеге мәгълүматларны бозып күрсәткән очракта, түбәндәге җаваплылык чаралары кулланылырга мөмкин:

1) кисәтү;
2) депутатны, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасын муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органында, җирле үзидарәнең сайланулы органында вазыйфадан азат итү, аның вәкаләтләре вакыты беткәнче, муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органында, җирле үзидарәнең сайланулы органында вазыйфа биләүдән мәхрүм итү.;
3) даими нигездә вәкаләтләрне гамәлгә ашырудан азат итү, аның вәкаләтләре вакыты беткәнчегә кадәр даими нигездә вәкаләтләрен гамәлгә ашыру хокукыннан мәхрүм итү.;
4) муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органында, җирле үзидарәнең сайланулы органында аның вәкаләтләре срогы тәмамланганчы вазыйфаларны биләүне тыю;;
5) вәкаләтләр срогы тәмамланганчы даими нигездә вәкаләтләрен үтәүне тыю.

4. Әлеге Нигезләмәнең 4.3 пунктында каралган җаваплылык чараларын куллану турында Татарстан Республикасы Президенты гаризасы (алга таба - җаваплылык чаралары) аларны куллану турында Карар кабул итәргә вәкаләтле җирле үзидарә органы тарафыннан әлеге органга гариза кергән көннән 30 көннән дә соңга калмыйча карала. Татарстан Республикасы Президенты гаризасын карау нәтиҗәләре буенча җаваплылык чарасын куллану яисә җаваплылык чарасын кулланудан баш тарту турында Карар кабул ителә.
Хисап чорында керемнәр, чыгымнар, милек һәм милек характерындагы йөкләмәләр турында дөрес булмаган яки тулы булмаган белешмәләр биргән өчен бары тик бер генә җаваплылык чарасы кулланылырга мөмкин.
Җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты, керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яки тулы булмаган белешмәләр биргән депутатка, күрсәтелгән затка карата җаваплылык чараларын куллану турында Карар кабул итәргә вәкаләтле орган тарафыннан аңа карата күрсәтелгән чараларны куллану турындагы мәсьәләне караганчыга кадәр биш эш көненнән дә ким булмаган вакыт эчендә җаваплылык чараларын куллану турындагы мәсьәләне карау турында хәбәр ителә.
Җаваплылык чарасын куллану турындагы карарда коррупциячел хокук бозуга күрсәтмә, депутат, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты тарафыннан бозылган норматив хокукый актлар нигезләмәләре, Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә карарга карата шикаять бирү хокукы булырга тиеш.
Җаваплылык чарасын кулланудан баш тарту турындагы карарда мондый баш тартуның дәлилләнгән дәлиле булырга тиеш.
Җаваплылык чарасын куллану яисә җаваплылык чарасын кулланудан баш тарту турындагы карарның күчермәләре аны кабул иткән көннән биш эш көне эчендә депутатка, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасына, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затына имза астында тапшырыла яисә тапшыру турында уведомление белән почта аша җибәрелә, шулай ук Татарстан Республикасы Президентына җибәрелә.
Җаваплылык чарасын куллану яисә җаваплылык чарасын кулланудан баш тарту турындагы карар Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә шикаять бирелергә мөмкин.

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль
районы Камай авыл җирлеге Советының
2021 ел 10 нчы июненнән 33 номерлы карарына
2 НЧЕ КУШЫМТА

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Камай авыл җирлеге муниципаль вазыйфа яисә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар, муниципаль вазыйфалар яисә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфаларын биләүче затларның, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре,чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирү мәҗбүри булган дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары
ИСЕМЛЕГЕ

Глава Камаевского сельского поселения Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Камай авыл җирлеге башлыгы

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Камай авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Камай авыл җирлеге Советы депутатлары.

«Муниципаль вазыйфа яисә контракт
буенча җирле администрация башлыгы
вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар,
муниципаль вазыйфалар яисә контракт
буенча җирле администрация башлыгы
вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан
керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм
мөлкәти характерындагы йөкләмәләре
хакында белешмәләр бирү тәртибе
турында» Нигезләмәгә кушымта

Татарстан Республикасы Президентына
________________________________

Хәбәрнамә

Мин_____________________________________________________авыл җирлеге депутаты
авыл җирлегенең вәкиллекле органы исеме
_______________________________________________________________муниципаль район
муниципаль район исеме
_______________________________________________________________________________,
фамилиясе, исеме һәм (булса) атасының исеме
«___»________________________туган елы, паспорт сериясе _________________________
№_______________, _______________________________________________________________
бирү датасы һәм паспорт биргән орган
________________________________________________________________________________,
«Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 121 статьясындагы 42 өлеше һәм «Муниципаль вазыйфа яисә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар, муниципаль вазыйфалар яисә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характерындагы йөкләмәләре хакында белешмәләр бирү тәртибе турында» 2017 елның 19 июлендәге 56-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясындагы 41 өлеше нигезендә, минем, хатыным (ире) һәм (яки) балигъ булмаган балаларының № 230-ФЗ «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен контрольдә тоту турында» (җир кишәрлеге, башка күчемсез милек объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр, акцияләр (оешмаларның устав (җыелма) капиталларында катнашу өлеше, пайлары) сатып алу буенча алыш-бирешләр), аларның гомуми суммасы тормыш иптәшем (хатыным) кеременнән соңгы өч ел эчендә артып китә), хисап чоры дәвамында 1 гыйнвардан 31 декабрьгә кадәр булмады.
Әлеге белешмәләрнең дөреслеген раслыйм.

«____»______________20__ел _________________________________________
гариза биргән зат имзасы

_________________________________________________________________________
(хәбәрнамәне кабул итүгә вәкаләтле затның фамилиясе, исеме һәм (булса)әтисенең исеме, имзасы)